РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14 февраль 2020 ел Буа шәһәре 50/ик-п номерлы

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
территориясендә хуҗасыз хайваннарны тоту,
карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибенә
үзгәрешләр кертү турында

Буа муниципаль районы территориясенең тиешле санитар торышын, халыкның сукбай йорт хайваннарының тискәре йогынтысыннан иминлеген тәэмин итү, кеше һәм хайваннар өчен уртак йогышлы һәм инвазион авыруларны профилактикалау, сукбай хайваннарның санын җайга салуның гуманлы алымнарын куллану максатларында, 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон, 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы "Халыкның санитар-эпидемиология иминлеге турында", 2018 елның 27 декабрендәге 498–ФЗ номерлы "Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм РФнең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль закон, 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы "Ветеринария турында" Россия Федерациясе Законы, 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы "2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында" Татарстан Республикасы Законы, 2009 елның 1 ноябрендәге 995 номерлы "2000 елның 5 июлендәге 470 номерлы Татарстан Республикасында социаль стандартларны һәм натураль нормаларны үстерү турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында ветеринария хезмәте учреждениеләрен тоту чыгымнарының социаль стандартларына һәм натураль нормаларына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2009 елның 29 апрелендәге 202/ИК-п номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибен раслау турында» боерыгы белән расланган Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 2.2 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Хуҗасыз хайваннарны тоту вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән заказ-хуҗасыз хайваннарны тоту буенча эшләрне башкаруга беррәттән, физик һәм юридик затларның (алга таба – гариза бирүче) язмача мөрәҗәгатьләре нигезендә, шулай ук вәкаләтле орган белән төзелгән контрактлар (шартнамәләр) шартларына туры китереп, хуҗасыз хайваннарны тоту буенча планлы чаралар нигезендә башкарыла.»;

1.2. 4.7 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7. Мәҗбүри тәртиптә дегельминтация үткәрелергә һәм сукбай хайваннарның котыру авыруына каршы вакцинация ясалырга тиеш.»;

1.3. 4.10 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.10. Хуҗасы барлыгын күрсәткән билгеләре ( тамгасы, электрон тәңгәлләштерү

саны, муенчагы яхшы токымнан булу) булган хайваннар тотылган очракта, махсуслаштырылган оешма өч көн дәвамында массакүләм мәгълүмат чараларында, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кешегә караган билгеләр булган хайван турында белдерү урнаштыра, ә идентификацияләү очрагында, хайванның урнашу урыны турында кичекмәстән хуҗага барлык мөмкин булган ысуллар белән хәбәр итә һәм аның таләбе буенча кире кайтарыла.»;

1.4. 4.12 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.12. 4.10 пунктта күрсәтелгәннәрдән тыш, хуҗасыз хайваннар, күрсәтелгән процедураны үткәргәннән соң, әлеге Тәртип нигезендә, элеккеге яшәү урыннарына кире кайтарылырга тиеш. Махсуслаштырылган оешма, гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә, сукбай хайваннарны тиешле тәртиптә тоту өчен җаваплы.»;

1.5. 4.14 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.14. Махсуслаштырылган оешма сукбай хайваннарның хуҗаларын массакүләм мәгълүмат чараларында, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә хуҗасыз хайваннарны тотканнан соң өч көн эчендә игълан итү юлы белән эзләү буенча чаралар күрә.»;

1.6. 5.1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннарның санын җайга салу методлары булып тора:

а) хуҗасыз хайваннарны стерилизацияләү (кастрацияләү);

б) әлеге Тәртипнең 5.7 пунктында каралган нигезләр буенча хуҗасыз хайваннарның тиз һәм авырттырусыз үтерелүе;

в) Махсуслаштырылган оешмаларның вакытлыча тоту пунктларында (приютларда) тоту һәм карап тоту.»;

1.7. 5.7 пунктның а) пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) югары агрессив хуҗасыз хайваннар, алар белән кеше котыру авыруына бәйле шикле очрак ;»;

1.8. Түбәндәге редакциядә бәян итеп ( Тәртипкә 5 нче кушымта) махсуслаштырылган оешмаларга хуҗасыз хайваннарны тоту, транспортлау, карап тоту, исәпкә алу һәм җайга салу чараларын тормышка ашыруга чыгымнар нормалары стандартларын расларга:

| Махсуслаштырылган предприятиеләргә хуҗасыз хайваннарны тоту, транспортлау, карап тоту, исәпкә алу һәм җайга салу чараларын тормышка ашыру чыгымнары нормалары стандартлары | |
|---|---|
| Норма исеме | Бер хайванга норманың әһәмияте, сум* |
| Хуҗасыз хайванны тоту | 350,92 |
| Хуҗасыз хайванны вакытлыча тоту пунктына транспортировкалау һәм аны табигый яшәү тирәлегенә кайтару ** | 387,72 |
| Дәвалау-профилактика чаралары (вакцинация, дегельминтизация, дезинсекция) | 538,40 |
| Хуҗасыз хайванны вакытлыча тоту пунктында 1 календарь көн тоту | 108,99 |
| Хуҗасыз хайванны стерилизацияләү (ана җенесле) | 1003,91 |
| Хуҗасыз хайванны кастрацияләү (ата җенесле) | 769,72 |
| Яшәүгә сәләтсез хайваннарның тиз һәм авырттырусыз үтерелүе һәм утилизацияләү ( хайванның авыр дәваланмый торган авыруы яки авыр җәрәхәт алуы булганда, хайван тормышы белән туры килми торган кискен җәрәхәт булганда ) | 773,31 |
| * 2020 елның 1 июленә карата бәяләрдә . | |

** Финанс ягыннан тәэмин итү күләме бригада чыгу өчен бер үк вакытта транспортлана торган хайваннар саныннан чыгып исәпләнә.

2. . Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә йөклим.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Камартдинов